КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 2 июль г.Казань № 525

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 22 август, 407 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 22 август, 407 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 22 декабрь, 912 нче; 2010 ел, 19 июль, 577 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 7 февраль, 88 нче; 2012 ел, 12 октябрь, 847 нче; 2013 ел, 21 март, 196 нчы; 2013 ел, 11 июнь, 399 нчы; 2013 ел, 28 июнь, 446 нчы; 2013 ел, 29 август, 612 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 21 нче; 2014 ел, 1 март, 133 нче; 2014 ел, 18 апрель, 255 нче; 2014 ел, 8 октябрь, 742 нче; 2015 ел, 22 гыйнвар, 28 нче; 2015 ел, 9 февраль, 72 нче; 2015 ел, 6 июль, 490 нчы; 2016 ел, 30 апрель, 269 нчы; 2016 ел, 9 июнь, 382 нче; 2016 ел, 12 октябрь, 737 нче; 2016 ел, 23 декабрь, 977 нче; 2017 ел, 6 март, 130 нчы; 2017 ел, 26 июнь, 439 нчы һәм 2017 ел, 7 декабрь, 950 нче; 2018 ел, 14 март, 151 нче; 2018 ел, 11 июнь, 461 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1139 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 нче пунктта:

3.3.26 нчы пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.26. Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турындагы, авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдәге җир кишәрлекләрен башка категориягә күчерү турындагы үтенечнамәләрне карап тикшерә, Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында, Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен, муниципаль, хосусый милектә булган авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдәге җир кишәрлекләрен, дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү (законнар белән күздә тотылмаган очраклардан тыш) турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларын әзерли.»;

3.3.82 нче пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.82. Газ бүлү челтәрләренең саклау зоналарын билгеләү, аларга үзгәреш кертү, аларның булуын бетерү турында карарлар кабул итә.»;

3.3.103 нче пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.103. Эшчәнлекнең билгеләнгән өлкәсендә законнар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры　　　　　　　　　　　　　　　　А.В.Песошин